КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 26 гыйнвар г.Казань № 45

«Физик-химик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 нче сыйныфларында белем алучыларга акчалата бүләкләү бирү турында

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының физика, химия, биология белән шөгыльләнүче белем алучыларының табигый-фәнни белем өлкәсендә үз талантларын һәм сәләтләрен алга таба камилләштерүгә мотивациясен арттыруга юнәлдерелгән «Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Физик-химик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 нче сыйныфларында белем алучыларга акчалата бүләкләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәне;

«Физик-химик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 нче сыйныфларында белем алучыларның акчалата бүләкләү алучылар санын һәм күләмнәрен.

2. Бу карар нигезендә «Физик-химик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 нче сыйныфларында белем алучыларга акчалата бүләкләү түләү чыгымнары «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2025 елның 29 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законында «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» ведомствосы буенча әлеге максатларга каралган акча исәбеннән башкарыла.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 26 гыйнвар, 45 нче
карары белән расланды

# «Физик-химик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 нче сыйныфларында белем алучыларга акчалата бүләкләү бирү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә «Физик-химик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген башкара торган гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 нче сыйныфларында белем алучыларга (алга таба – белем алучылар) «физика», «химия», «биология» предметларын актив һәм нәтиҗәле өйрәнгән өчен акчалата бүләкләү бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә аннан файдалану максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

акчалата бүләкләү алырга теләүче – акчалата бүләкләү алу өчен сайлап алуда катнашу өчен заявка биргән белем алучы;

акчалата бүләкләү – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырыла торган акчалата бүләкләү алу өчен конкурс нигезендә сайлап алу (алга таба шул ук эзлеклелектә – Министрлык, сайлап алу) йомгаклары буенча акчалата бүләкләү алучы дип танылган акчалата бүләкләү алырга теләүчегә бер тапкыр бирелә торган түләү;

акчалата бүләкләү алучы – сайлап алу йомгаклары буенча акчалата бүләкләү бирү турында карар кабул ителгән акчалата бүләкләү алырга теләүче.

3. Акчалата бүләкләү бирү максатлары:

белем алучылар арасында физика, химия, биология өйрәнүне популярлаштыру;

физика, химия, биология өйрәнүче белем алучыларны үз талантларын һәм сәләтләрен алга таба үстерүгә мотивацияләү;

инициативалы белем алучыларга аларның табигый-фәнни белем бирү өлкәсендә потенциалны үстерү һәм гамәлгә ашыру омтылышларына кирәкле ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

югары белем бирү мәгариф оешмаларының һәм (яки) һөнәри белем бирү оешмаларының табигый-фәнни, техник һәм технологик юнәлешенә керүгә юнәлдерелгән белем алучыларны комплекслы әзерләүгә ярдәм итүне тәэмин итү.

4. Сайлап алуда катнашырга бер үк вакытта түбәндәге шартларга туры килә торган белем алучыларга рөхсәт ителә:

Министрлык боерыгы белән расланган критерийлар нигезендә уку предметлары буенча өлгереп бару;

Министрлык боерыгы белән расланган предмет (предметлар) һәм сроклар буенча Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен лицензиясе булган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган түгәрәктә һәм (яки) өстәмә белем бирү программасында уку;

Министрлык боерыгы белән расланган исемлек нигезендә кимендә бер казанышы булу;

Министрлык боерыгы белән расланган критерийлар нигезендә предметлар буенча укуын дәвам итүдә кызыксынуын күрсәтү.

5. Сайлап алуда «физика», «химия», «биология» предметлары буенча агымдагы һәм узган уку еллары өчен Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының, халыкара олимпиадаларның йомгаклау этабында җиңүче һәм (яки) приз алучы белем алучылар катнаша алмый.

6. Әгәр белем алучы бер үк вакытта «Физик-математик алгарыш» һәм «Физик-химик алгарыш» проектларын гамәлгә ашыру кысаларында акчалата бүләкләү алуга сайлап алуда катнашса, бүләкләү алу иң күп җыелган баллар нигезендә сайлап алуларның берсендә генә алынырга мөмкин. Сайлап алуның икесендә дә акчалата бүләкләү алу каралмый.

7. Заявкаларны кабул итү сроклары, заявкалар кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыручы оператор (алга таба – оператор) турында белешмәләр, сайлап алуны үткәрү тәртибе һәм сроклары, сайлап алуда катнашуга заявка (алга таба – заявка) формасы, акчалата бүләкләү алырга теләүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык формасы Министрлык боерыгы белән раслана.

8. Заявкаларны кабул итү һәм теркәү өчен Министрлык тарафыннан Министрлыкның ведомство буйсынуындагы оешмалар арасыннан оператор билгеләнә.

9. Министрлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта (алга таба – рәсми сайт) түбәндәгеләрне бастырып чыгаруны тәэмин итә:

акчалата бүләкләү бирү шартлары, акчалата бүләкләү алырга теләүчеләргә карата таләпләр, заявкалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы, оператор турында белешмәләр бирелергә тиешле сайлап алуны үткәрү турында белдерү – заявкалар бирү датасына кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча;

сайлап алу сроклары, заявка составында тапшырыла торган документлар исемлеге белән заявканың формасы, акчалата бүләкләү алырга теләүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык формасы, анкета формасы, шулай ук заявкалар бирү адресы һәм ысулы – заявкалар бирә башлау датасына кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча;

Министрлыкның акчалата бүләкләү алырга теләүчеләрне сайлап алу буенча конкурс комиссиясе беркетмәсе (алга таба шул ук эзлеклелектә – конкурс комиссиясе, конкурс комиссиясе беркетмәсе) нигезендә кабул ителә торган акчалата бүләкләү бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында боерыгы – аны чыгару датасыннан алып өч эш көне эчендә.

10. Сайлап алуда катнашу өчен акчалата бүләкләү алырга теләүчеләр операторга заявка һәм заявка составында түбәндәге документларны тапшыра:

туу турында таныклык күчермәсен яисә Россия Федерациясе гражданы паспорты күчермәсен;

Россия Федерациясе гражданының салым түләүче идентификация номеры

күчермәсен;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасыннан белем алучының өлгереше турында белешмә кәгазен;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасыннан акчалата бүләкләү алырга теләүченең Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган табигый-фәнни юнәлештәге түгәрәктә һәм (яки) өстәмә белем бирү программасында кимендә 6 ай дәвамында катнашуын раслый торган белешмә кәгазе;

Министрлык боерыгы белән расланган исемлек нигезендә олимпиадалар, конкурсларда һәм чараларда җиңүче, приз алучы яки катнашучылар дипломнары күчермәләрен;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сорауларга җаваплар белән анкета.

Акчалата бүләкләү алырга теләүче заявканы кәгазьдә тутыра һәм сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән срокларда турыдан-туры тапшыра яисә почта аша җибәрә.

Тиешле техник мөмкинлекләр булганда, Министрлык карары буенча заявкаларны бирү Россия Федерациясе законнары (шул исәптән шәхси мәгълүматларны саклау өлкәсендә) таләпләрен үтәү шарты белән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып оештырылырга мөмкин.

Сайлап алу өчен бирелгән заявка һәм заявка составындагы документлар акчалата бүләкләү алырга теләүчеләргә сайлап алу тәмамланганнан соң кире кайтарылмый.

11. Операторга бирелгән заявка һәм аның составындагы документлар кергән көненнән алып бер эш көне эчендә теркәлә һәм конкурс комиссиясенә тапшырыла.

12. Заявка һәм аның составында тапшырылган документларны карап тикшерү конкурс комиссиясе тарафыннан заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Сайлап алу конкурс комиссиясе тарафыннан заявка составында акчалата бүләкләү алырга теләүче тарафыннан тапшырылган документларга Министрлык боерыгы белән расланган бәяләү критерийлары нигезендә бәя бирүдән гыйбарәт. Конкурс комиссиясенең карары конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре тарафыннан имзалана торган конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

13. Конкурс комиссиясе составы Министрлык боерыгы белән раслана. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкилләре, гомуми белем бирү өлкәсендәге белгечләр, педагогика, физика, химия, биология өлкәсендәге галимнәр, җәмәгатьчелек вәкилләре арасыннан кимендә биш әгъза составында төзелә. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкилләре саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми составының яртысыннан артмаска тиеш. Конкурс комиссиясе төзелгәндә конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре билгеләнә. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның функцияләрен конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

14. Акчалата бүләкләү алырга теләүчегә сайлап алуда катнашырга рөхсәт итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы булмаган комплектта тапшыру), һәм (яки) документларында бирелгән мәгълүмат дөрес булмау;

акчалата бүләкләү алырга теләүче әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән шартларга һәм әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында билгеләнгән таләпкә туры килмәү;

заявканы һәм (яки) документларны заявкаларны бирү срогы тәмамланганнан соң тапшыру;

агымдагы уку елында «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында акчалата бүләкләү алу.

Акчалата бүләкләү алырга теләүчегә сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителмәгән очракта, конкурс комиссиясе әлеге карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә операторга, сәбәпләрен күрсәтеп, акчалата бүләкләү алырга теләүчегә сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителмәү турында хәбәрнамә җибәрә. Оператор заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчалата бүләкләү алырга теләүчегә заявкада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча, сәбәпләрен күрсәтеп, акчалата бүләкләү алырга теләүчегә сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителмәү турында хәбәрнамә җибәрә.

15. Әлеге Нигезләмәнең 12 пункты нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча әлеге Нигезләмәнең 4 пункты нигезендә конкурс комиссиясе тарафыннан заявкалар бәяләнү нәтиҗәләре буенча сумма кимү тәртибендә акчалата бүләкләү алырга теләүчеләрнең ранглы исемлеге төзелә. Сайлап алуда җиңүчеләр дип сайлап алу йомгаклары буенча иң күп балл җыйган, ранглы исемлектә түбәндәге урыннарны биләгән акчалата бүләкләү алырга теләүчеләр таныла:

5 – 6 нчы сыйныфларда белем алучылар – 1 нче урыннан 50 нче урынга кадәр;

7 нче сыйныфта белем алучылар – 1 урыннан 30 урынга кадәр;

8 – 11 нче сыйныфларда белем алучылар – 1 нче урыннан 120 нче урынга кадәр.

Акчалата бүләкләү алырга теләүчеләрнең рангларга бүленгән исемлеге конкурс комиссиясе беркетмәсенә теркәлә һәм кул куелган датадан алып биш эш көне эчендә Министрлыкка җибәрелә.

Министрлыкның сайлап алу йомгаклары турында боерыгы Министрлык тарафыннан конкурс комиссиясе беркетмәсе алынган датадан алып биш эш көне эчендә раслана.

16. Акчалата бүләкләү бирү Министрлык тарафыннан, акчалата бүләкләү бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 45 эш көненнән дә соңга калмыйча, акчаны акчалата бүләкләү алучыларның Россия кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

17. Акчалата бүләкләү алу өчен акчалата бүләкләү алучылар яки аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) Министрлыкка, акчалата бүләкләү бирү турында карар кабул ителгән датадан алып 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, ирекле формада язылган акчалата бүләкләү күчерү турында гариза җибәрә, әлеге гаризада түбәндәге мәгълүмат бирелергә тиеш:

акчалата бүләкләү алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда);

акчалата бүләкләү алучының салым түләүче идентификация номеры, индивидуаль шәхси счетының иминият номеры;

акчалата бүләкләү алучының Россия кредит оешмасында ачылган банк счеты реквизитлары.

Министрлык, әлеге гаризаны алганнан соң, әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында билгеләнгән сроктан да соңга калмыйча, акчалата бүләкләү түләүне гамәлгә ашыра.

___________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 26 гыйнвар, 45 нче
карары белән расланды

«Физик-химик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында
Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү
оешмаларының 5 – 11 нче сыйныфларында белем алучыларның
акчалата бүләкләү алучылар саны һәм күләмнәре

| Т/с | Алучылар категориясе | Алучылар саны, кеше | Бер белем алучыга акчалата бүләкләү күләме, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 6 нчы сыйныфларында белем алучылар | 50 | 69,0 |
| 2. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 7 нче сыйныфларында белем алучылар | 30 | 69,0 |
| 3. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8 – 11 нче сыйныфларында белем алучылар | 120 | 69,0 |

______________________________